**СОВЕТ ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422612 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПӘРӘҮ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422612 Пәрәү авылы,
Совет урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

---

**2026елның 09 апреле** **35 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында»гы 1009 нчы номерлы Указының 4 нче пунктына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип таныйрга:

1)Пәрәү авыл җирлеге Советының 2023 елның 17 гыйнварындагы «Пәрәү авыл җирлеге Советының 2016 елның 18 апрелендәге «Пәрәү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләргә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти төстәге йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итүләре, шулай ук Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти төстәге йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итүләре турында»гы 24 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 1 нче номерлы карарын.;

2) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Пәрәү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти төстәге йөкләмәләр турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү тәртибен раслау турында»гы 55 нче номерлы карарын;

3)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советының 2014 елның 22 декабрендәге «Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләргә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тәкъдим ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, шулай ук Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне саклаулары турындагы Положениене раслау турында»гы 78 нче номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://laishevo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Пәрәү**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Ф.Ф.Тимергалиев**